**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7224**
**03.11.2021**

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары (Башкарма комитетның 2019 елның 8 ноябрендәге 5758 номерлы, 2019 елның 27 ноябрендәге 6143 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы 1709 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына, 6 бүлектә 4 нче бурычны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 3 ноябрендәге
7224 номерлы карарына
кушымта

| № т/б | Чараларның исеме | Башкаручылар | Тормышка ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганаклары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел (бәяләү) | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Бурычның исеме: 4. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин ителеше | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарылган милләтара һәм динара конфликтлар элементларын үз эченә алган мәкаләләр саны | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Басылып чыккан мәкаләләр саны, берәмлек | - | - | Фактта | Фактта | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлекне саклау өчен уңай атмосфера булдыру |
| 2 | Дини оешмалар һәм культ корылмалары турында мәгълүматлар банкын квартал саен формалаш тыру һәм актуальләштерү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Мәгълүматлар базасын яңартуларның саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлекне саклау өчен уңай атмосфера булдыру |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Туган телдә (татар, рус) иң яхшы дәресләр, чаралар үткәрү буенча җыентык бастырып чыгару | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2019-2021 еллар | Данәләр саны | 100 | 100 | 100 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 4 | Шәһәрнең рәсми сайтында nabchelny.ru һәм шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында чараларны анонслау, пост-релизлар бастырып чыгару | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Басылып чыккан мәкаләләр, анонслар, телетапшырулар, интервью һәм чыгышлар саны | 15 | 16 | 17 | 18 | - | - | - | - | Толерантлык идеяләрен пропагандалау һәм тарату, милләтара һәм конфессияара бердәмлекне саклау өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева